


# «ШКОЛЬНЫЙ ВЕСТНИК»

***МБОУ «СОШ №3» г.Мензелинск***

***ноябрь, 2017г.***

Газетаның бу саны Әниләр көненә багышлана.

Ана булу-изгелекнең тажы,
Дөньяда иң олы дәрәҗә...




**Васильева Елизавета, 9 нчы сыйныф**

“Әни сүзе- һәр кешенең иң беренче сүзе. Бу олы сүз кешенең соңгы көннәренә кадәр яши. Әни авырлыклары булса да, һәрвакыт янәшәдә була. Ул һәр эштә ярдәм кулын суза. Әнисез яшәү бик авыр, тик ул гына сиңа карата ягымлы, кайгыртучан була бит. Минем барлык җиңүләрем әни ярдәме белән ирешелгән. Шуңа күрә яраткан әниләребезне сакларга һәм хөрмәт итәргә кирәк”.

**Ханова Алсу, 8 нче сыйныф укучысы**

Әниемнең кояш кебек нурлы йөзе,
Алтынга тиң аның һәрбер әйткән сүзе.
Киләчәктә эти белән, безнең белән
Бик бәхетле булсын иде инде үзе.

**Исламова Лилия, 9 нчы сыйныф**

“Әннә” диеп аваз сала сабый
Бу дөньяга күзен ачканда.
Тора- бара “әннә” “әни” була,
Сабый үсә, сүз дә үзгәрә.
Сүз үзгәрә, ләкин бер үк мәгънә,
Шул ук кеше кала барыбер...
Бала чакта, олыгайгач та бит,
“Әни!”,”Әнкәй!”- ди бит
күңелебез.

Әни исемен йөртү- олы исем.
Икеләтә олы ул сезгә.
Сәламәтлеге чикле бала
тәрбияләү,
Авыр сынау бит ул әнигә.
Ләкин ходай саулык-
сәламәтлекне
Тигез бирми һәрбер сабыйга...
Әниле сабыйлар гына
Тормыш матурлыгын күрә ала.

**Әнием.**
**Җәләева Азалия, 3нче сыйныф**

Әни сүзе- нинди бөек сүз ул.
Күпме мәгънә ята бит анда.
Әни- тормыш, әни-яшәү яме,
Әни бит ул яши һәр җанда.

Тәмле чәе, якты йөзе белән
Каршы алса сине мәктәптән.
Бөтен ару-талу юкка чыга кебек
Көннәр тора бары шатлыктан.

Ничек рәхәт янда әни булса,
Күңел тыныч, дөнья күңелле.
Аның исән-сау булуын күрү,
Шушы үзе бәхет түгелме?

Телим , әнием сиңа озын гомер
Сәламәт бул, яшә бәхеттә
Әти белән бергә парлы тормыш
көтеп
Урыныгыз булсын тәхеттә!!!

**Тимиркаев Ренат, 5нче сыйныф укучысы**

Кем иртән иркәләп уята?
Кем сөеп , яратып карый?
Инде дәү булып үссәк тә,
Һаман балага саный?
Ул – безнең әниләребез,
жирдәге фәрештәләр.
Жил-давылдан саклаучы
Олы йөрәкле кешеләр.

**Галеева Алина, 7 нче сыйныф укучысы**

Жир шарында әниләр күп,
Яраталар аларны.
Тик минем әнием-берәү ,
Шуңа сөям мин аны.



**Алина Фәтхуллина, 6нчы сыйныф укучысы**

Әни- иң якын кешем,
Яратканым , бердәнберем
Әни –өебезнең яме,
Ул минем иң кадерлем.
Йомшак кулы белән сыйпый
Мине әни шулай назлый.
Әни пешергәне иң тәмлесе-
Һәрвакыт ул безне сыйлый.



Галиев Рамис, 4 нче сыйныф

**Тимиркаев Риназ, 2 нче сыйныф укучысы**

Бу дөньяда иң кадерле кешем
Минем әнием бит ул.
Акыллы, уңган, булган,
Күзләрендә - якты нур.
Көн дә иркәләп уята,
Тәмле ашлар белән сыйлый.
Аңа булган чиксез рәхмәтем
Күңелләремә сыймый.

**Әнкәем**

**Шабаев Ирек, 2 нче сыйныф укучысы**

“Әнкәем, бердәнберем” дип
Эндәшәм әниемә.
Аннан да кадерле кеше
Юктыр ул бу дөньяда.
Аның шифалы куллары
Авыр чакта дәвалый,
Киңәшләре яклыйдыр
Барлык авырлыклардан.



Потапова Вероника, 4нче сыйныф

**Богер Даниил, 6 нчы сыйныф укучысы**

Синең әниең яхшы,
Минем әни –яхшырак.
Мин әнине яратам,
Әнигә рәхмәт.





**Федотова Эльвина, 7 нче сыйныф**

Минем әнием!
Сине бик яратам,
Матур чәчәкләр алып,
Сиңа бүләк итәм.

**Данилова Екатерина, Киселева Алена,**
**Петрова Анастасия, 5 нче сыйныф**

Әнием минем,  сине яратам
Һәм чәчәкләр бүләк итәм.
Син матур һәм акыллы
Лалә чәчәге төсле.
Зур авырлыклар булган
Һәм син аларны җиңгән.

**Шайхразеев Тимур, 4нче сыйныф**

Иң кадерле әнием минем
Син иң гүзәл кешем.
Сиздермичә ярдәм итәсең
Авыр чагымда минем.

**Кадерлем.**
**Родичева Злата, 6нчы сыйныф укучысы**

Әнинең куллары назлы,
Әнинең карашы ямьле.
Һәр минутта булыша,
Миңа ярдәмгә килә.
Әгәр күземне йомсам,
Таныйм аны тавышыннан
Ул кадерле барсыннан-
Әнием - берДәнберем!

**Әни.**
**Садриев Азамат, 2 нче сыйныф,**
**Садриева Аделина, 4 нче сыйныф**

Әни сүзе бик-бик борынгыдан
Тирән мәгънәле сүз булып килде.
Әни булган кеше-
Иң кадерле, иң бәхетле кеше.
Әни- иң зур кеше
Безнең дөньяда.
Язсын сиңа Ходай
Озын гомер яшәргә.



Зарипов Дамир

**Ильина Элина,4 нче сыйныф**

Кадерле әнием минем,
Бик матурым син.
Акыллы һәм игелекле кешем
Авыр вакытларымда
Гел янәшәмдә минем.

**Тимергалиева Ләйсән, 7 нче сыйныф**

Әниемне мин бик сөям,
Һәрвакыт ярдәм итәм.
Әнкәй- минем яраткан,
Бердәнбер якын кешем!
Әни мине кочаклады -
Шунда ук бәхетле булдым.

**Галиуллина Аида, 6нчы сыйныф укучысы**

Минем әнием,
Мин сине яратам!
Кемгә мин бүген
Бүләкне бирәм?
Әни,мә сиңа чәчәк
Һәм бик-бик тәмле чәкчәк.

**Мусина Камилла, 6 нчы сыйныф укучысы**

Нинди көч,
Нинди гайрәт,
Әнкәем йөрәгендә!
Иң йомшак, назлы сүзләр
Минем теләгемдә...
Үсеп буйга җиткәч,
Үзем
Әйтәм сиңа
Рәхмәт сүзен!

**Притчина Анастасия, 7 нче сыйныф укучысы**

Мин әнине яратам.
Ул - минем якын кешем.
Әни минем белән сөйләшә-
Бу һәрвакыт шатландыра.
Әнием кояш кебек күктә
Миңа һәрчак яктырта.
Һаман булыша,
Гафу итә һәрвакыт .
Минем өчен бар көчен
Кызганмый шул бәгърем.

**Соловьев Арсений , 4нче сыйныф**

26нчы ноябрь-
Кызыл көн календарьда
Бу көн- әниләр бәйрәме.
Сиңа, әни, бу көнне
Ак чәчәкләр бүләк итәм.
Булсын йөзеңдә һәрчак
Елмаюның балкышы.

**Зиазтдинов Риналь, 4 нче сыйныф**

Мин әниемне яратам!
Иртән торгач ул мине
Уята, үбә, кочаклый,
Матур сүзләр дә әйтә.
Син минем сандугачым,
Асыл кошым,
Син бит минем бөртегем!



**Зиазтдинов Риналь, 4 нче сыйныф**

**Елизаров Вадим, 2нче сыйныф**

Кояш кебек елмая,
Кояш кебек җылыта,
Кояш кебек балкып тора
Иң кадерле кешем әнием!
Чәчәктәй матур!
Мәхәббәте безгә бик зур,
Мин аны нык яратам
“Кадерлем”-диеп дәшәм!
Әнием-күз нурым,
Кадерлем, алтыным!
Дөньяда иң чибәр,
“Фәрештә ул”- диләр!

**Әнием.**
**Ильясова Карина, 2нче сыйныф**

Минем әни акыллы
Бәгърем һәм матурым.
Яратам мин әнине
Чөнки әни -минеке!

**Әнием.**
**Исламов Тимур, 2нче сыйныф**

Әнием гел балкып тора
Күктәге йолдыз кебек
Мин дә тырышам булырга
Газиз әнием кебек.
Иренә белми әнием
Көн буе эшләр карый
Күңелемне юатырга
Син бар бит әле ярый.
Өйрәтәсең һәр нәрсәгә
Зур сабырлыклар белән
Рәхмәт әйтеп тәбриклим
Әниләр көне белән!

**Кудряшова Арина 7нче сыйныф**

Әни- мөһим сүз дөньяда,
Әни безгә гомер бүләк итте.
Авыр минутларда миңа
Әни һәрчак ярдәм итте.
Ә мин аңа рәхмәт әйтәм
Һәм "Яратам сине!"- диям.



**Муллахметова Алия, 7нче сыйныф**

Минем әнием бик чибәр,
Ул мине бик ярата.
Иртән торып уята
Аннары эшкә китә.
Кичен ул өйгә кайта,
Тәмле бәлеш пешерә.
Минем әни- иң яхшысы,
Яратам аны шуңа!



**Габдуллина Алинә, 7 нче сыйныф укучысы**

Аларның куллары,
Аларның күзләре,
Аларның чәчләре-
Иң якын, иң матур.
Алар безне саклыйлар,
Безне бик яраталар.
Балалар! Яратыгыз әниләрегезне,
Онытмагыз аларның сүзләрен!

**Әниемә.**
**Журавлева Александра, 2нче сыйныф**

Әнием, сине яратам
Җырны сиңа җырлыйм.
Шигырьне сиңа сөйлим
Һәм өйдә булышам.

**Әни белән.**

**Панченко Богдан, 2нче сыйныф**

Әни белән безгә
Өйдә ямьле һәм тәмле.
Ул булмаса бу дөньяда
Кирәкми берни дә.
Әни булса көлә күңел,
Дөнья ямьләнә.
Әни кирәк, әни кирәк
Бөтен кешегә.



Гайнетдинова Ильвина, 4 нче сыйныф

**Гайнетдинова Ильвина, 4 нче сыйныф**

Әниемнең шатлыктан
Балкыды бит йөзләре.
Мин дә аңа кушылдым -
Кояш кебек елмайдым.
Елмайсам да урынлы:
Бүген әни бәйрәме.
“Мәңге яшә, әнием”, -
Дидем мин аңа бүген.

**Шарапова Дарья, 4нче сыйныф укучысы**

Әниемнең күзләре яшел,
Ә чәчләре бик кыска.
Эшеңдә югаласың син
Көннәр буена.



**Сидорова Дарья, 4 нче сыйныф укучысы**

Әнием, син кадерлем!
Авыр вакытларымда
Син гел янәшәмдә минем.
Мин бик яратам сине
Һәм горурланам.

**Бурганова Рената, Ильина Дарья,**
**5 нче сыйныф укучылары**

Әни, әни, син матур,
Зур матур чәчәк син!
Син бик кадерле кешем,
Чөнки үстергәнсең мине.

**Минем әнием.**
**Гыйлфанова Лилия, 4 нче сыйныф**

Уңган, булган һәм җитез
Аны кем дип уйлыйсыз?
Ул бит минем әнием,
Сез шуны да белмисез!



Гыйлфанова Лилия, 4 нче сыйныф

**Шихова Арина, 7 нче сыйныф**

Тиздән әни бәйрәме,
Кулларымда чәчәкләр.
Мин котлыйм әниемне,
Телим аңа бәхетләр.

**Киңәш.**
**Бигимова Виолетта, 6нчы сыйныф**

Әни- бит ул иң газизе.
Бу дөньяда бер генә.
Шуны аңлап , хөрмәт итеп,
Кадерләрен бел генә.

Өй эшләрендә булыш син,
Якты йөз белән сөйләш.
Сорау туса, туры юлны ,
Әниең белән киңәш.





Гаврилова Анастасия

**Әнием.**
**Акимова Эльвина, 2нче сыйныф**

Иртән иртүк йокыдан
Иркәләп  әнием уята.
Әни янда булганда рәхәт
Ул мине бар эшкә дә өйрәтә.



**Пилецкая Дарья, 2нче сыйныф**

Минем әниемнең исеме Юлия. Аның ике баласы бар: мин һәм минем апам Катя. Минем әнием бик акыллы һәм матур. Ул безгә бик тәмле ашлар пешерә. Без әниебезне бик нык яратабыз.



Валеев Ренат, 4нче сыйныф

**Әниемне яратам.**
**Валеев Айнур, 2нче сыйныф**

Әниемне яратам мин,
Аңа һәр көн елмаям
Әниемне яратам мин
Ансыз бер көн торалмам.
Көн дә җылы караш белән
Мәктәптән көтеп ала.



**Әни, рәхмәт!**
**Имамов Альмир, 9 нчы сыйныф**

Әнием, бик зур рәхмәт сиңа,
Күпме эшләр башкардың син, ничә еллар!
Мин кечкенә булганда да, зур үскәч тә,
Мине карап, мине көйләп үтеп киткән.

Хезмәтеңне онытмадым, онытмамын!
Сиңа ярдәм кирәк булса – булышырмын.
Ни телисең – синең өчен мин эшләрмен,
Рәхмәт сиңа, әнием минем, бик зур рәхмәт!

**Әниемә теләкләр.**

**Салдаев Данил, 2нче сыйныф**

Әниемнең җылы, назлы кулы
Безне саклап, назлап үстерә.
Көнелдәге изге теләкләре
Көтмәгәндә бәхет китерә.
Әниемнең гомере озын булсын,
Көләч, һәрчак шат булсын.
Безнең үскәнне күреп соклансын.

